ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2019 Казан шәһәре № 10-213/кс

«Лениногорск җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2020 елга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Лениногорск җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында җиткерелә торган кайнар суга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Лениногорск җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 13.12.2019
№ 10-213/кс карарына кушымта

Кайнар су белән тәэмин итүне хәл итүче «Лениногорск җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2020 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

<table>
<tr><td rowspan="3">т/с</td><td rowspan="3">Муниципаль берәмлек исеме, кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы</td><td colspan="4">Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тариф (ике компонентлы)</td></tr>
<tr><td colspan="2">Салкын суга компонент, сум/куб.м.</td><td colspan="2">Җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал</td></tr>
<tr><td>01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр</td><td>01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр</td><td>01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр</td><td>01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр</td></tr>
<tr><td></td><td>Лениногорск муниципаль районы</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td>«Лениногорск җылылык челтәрләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>1</td><td>Лениногорск шәһәре кулланучылары</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>1.1.</td><td>Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)*</td><td>30,44</td><td>31,62</td><td>2014,80</td><td>2057,45</td></tr>
<tr><td>1.2.</td><td>Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде)</td><td>25,37</td><td>26,35</td><td>1679,00</td><td>1714,54</td></tr>
<tr><td>2</td><td>Иске Иштирәк авыл җирлеге кулланучылары</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>2.1.</td><td>Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)*</td><td>20,92</td><td>21,14</td><td>2014,80</td><td>2057,45</td></tr>
<tr><td>2.2.</td><td>Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде)</td><td>17,43</td><td>17,62</td><td>1679,00</td><td>1714,54</td></tr>
</table>

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге